**Фәрид Сәлман**

# АЯТЕЛ - КӨРСИ ТӘФСИРЕ

**Хузур - 1434/2014**

www.darulkutub.com

**Фәрид Сәлман**
**АЯТЕЛ - КӨРСИ ТӘФСИРЕ**, Казань, 2014. - 64 стр.

Одобрено к печати решением №____
экспертного совета ЦРО-ДУМ РТ

**© Издательство «Хузур-спокойствие», 1434/2014**

Формат 84x108 1/32 , печатных листов: ?,?;
бумага офсетная, печать офсетная, тираж 3 000 экз.
Издание выпущено при поддержке издательства “Культурные ценности”
г Казань, пр Победы, 30, тел.: 251 47 88 электронная почта: ipk_ppk@mail.ru

типография «Астор и Я» г Казань Ахтямова 13а
Отпечатано в соответствии с предоставленным
электронным материалом.

www.darul-kutub.com

بسم الله الرحمن الرحيم

www.darul-kutub.com

## Бисмил - ләһир-рахмәнир-рахим

Әл-Хәмдү лил-ләһи раббиль - гъаләмин , галәмләрне юктан бар итеп яраткан һәм тәрбия кылган Раббыбыз, Аллаһы Тәгаләгә барча хәмед - сәнәләребез булсын!

Әс - Саләтү үәс - сәламү гъалә сәййидинә үә хәбибинә Мухәммәдин Расүлил -ләһи үә гъалә алиһи үә әсъхәбиһи әҗмәгъыйн яки әфәндебез вә хәбибебез Мөхәммәд галәйһис - сәламгә, аның әһле- бәйтенә, барча сахәбәләренә Раббыбызның иксез - чиксез салават - сәламләре булса иде! Амин!

**Аятел -Көрси тәфсире, хасыятьләре, шифасы**

بسم الله الرحمن الرحيم

الله لا إله إلا هو الحي القيوم ۝ لا تأخذه سنة

ولا نوم له ما في السموت وما في الأرض من ذا الذي يشفع

عنده إلا بإذنه يعلم ما بين أيديهم وما خلفهم ولا يحيطون

بشيء من علمه إلا بما شاء وسع كرسيه السموت والأرض

ولا يؤده حفظهما وهو العلي العظيم ۝

www.darul-kutub.com

## Аятел-Көрси

(«Әл-Бәкараһ» сүрәсе, 255 нче аять)

Әлла́һү лә̱́ иләһә и́ллә һү
әл-хә́йййүл-к̱а́йййүм
лә́ тәьх̱ү́ʒүһү си́нәтүў ўә лә́ нә́ўм
лә́һү мә́ фи́с-сәмә́ўә́ти ўә мә́ фи́л-әрдъ
мәң ʒә́л-ләʒи́ йә́шфәгъу гъы́йңдәһү́ и́ллә́ би – ’иʒниһ
йә́гъләмү мә́ бә́йнә әйди́һим ўә мә́ х̱а́льфәһүм
ўә лә́ йүхи́т̱ү́нә би-шә́й’им мин гъы́йльмиһи̱ и́ллә би́мә́ шә̱́’
ўә́сигъа күрси́йййүһүс-сәмә́ўә́ти ўәл- ә́рдъ
ўә лә́ йә’үдүһү хифз̱ү́һүмә
ўә һүўәл-гъали́йййүл-гъаз̱ы́йм.

## Гомуми мәгълүмат

Аятел – Көрси яки Көрси аяте Коръәне – Кәримнең әл – Бәкараһ сүрәсендә урнашкан.
Сүрә эчендә бу аятьнең саны – 255 - нче аяттер.
Бу аяттәге сүзләр 170 хәрефтән тора, сүзләр саны исә 50 – дер. Хәреф - хәрәкәләр дә, сүзләр дә Коръәне – Кәримнең хәзрәти Госман ( разыял – лаһү ганһе) чорында гамәлгә кабул ителгән язу кануннары вә тәртипләре белән язылган.
Бу язманы “ әр – Рәсем әл – Госмани” дип атыйлар.
Чагыштырып карагыз : аяттәге “ әс - сәмә́ўә́т ” сүзе хәзерге заман гарәп язуы тәртипләре буенча

أَلسَّمَاوَاتُ

дип язылса, Коръәне – Кәримнең шул искә алган “әр – Рәсем әл – Госмани” тәртипләре белән язылганда бу сүз

اَلسَّمٰوٰتُ

кыяфәтенә керер. Күренә ки, “әр – Рәсем әл – Госмани” белән язылганда ике “әлиф” хәрефе “ югалып калганнар”.Шуңа күрә аяттәге сүзләрнең хәрефләр саны бер исәп белән исәпләгәндә - 170, икенче исәп белән исәпләсәң 185 булып чыга.

## Аятьнең өлешләре

Аятел – Көрси бер аять кына булса да , Коръәне – Кәримнең кайбер сүрәләрдән дә зурырактыр. Әйтик, әл – Кәүсәр сүрәсе белән Аятел – Көрсине чагыштырып карагыз!

Кәүсәр сүрәсе 3 аяттән тора:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

إِنَّآ أَعْطَيْنٰكَ الْكَوْثَرَ ۝١ فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ۝٢ إِنَّ شَانِئَكَ هُوَ الْأَبْتَرُ ۝٣

www.darul-kutub.com

Аятел – Көрси исә үзе бер аять:

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

اَللّٰهُ لَآ اِلٰهَ اِلَّا هُوَ الْحَىُّ الْقَيُّومُ ۚ لَا تَاْخُذُهٗ سِنَةٌ

وَلَا نَوْمٌ لَهٗ مَا فِى السَّمٰوٰتِ وَمَا فِى الْاَرْضِ مَنْ ذَا الَّذِى يَشْفَعُ

عِنْدَهٗٓ اِلَّا بِاِذْنِهٖ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ اَيْدِيهِمْ وَمَا خَلْفَهُمْ وَلَا يُحِيطُونَ

بِشَىْءٍ مِنْ عِلْمِهٖٓ اِلَّا بِمَا شَآءَ وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمٰوٰتِ وَالْاَرْضَ

وَلَا يَؤُدُهٗ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِىُّ الْعَظِيمُ ۞

Аятел – Көрси зур, укылышы буенча озын булган сәбәпле, аятьнең эчендә берничә тукталыш яки вакыф бар. Бу тукталышлар саны – 10.

Әлл**а́**һү л**ә́** илә́һә и́ллә һ**ү** ( вакыф җә’из )
әл-хә́ййүл-к̲айй**ү́**м ( вакыф җә’из )
лә́ тәьх̲у́ꙁүһү си́нәтү**ў** ўә л**ә́** нә́ўм ( вакыф җә’из )
лә́һ**ү** м**ә́** ф**и́**с-сәм**ә́**ў**ә́**ти ўә м**ә́** ф**и**л-әрдъ ( вакыф мотлак )
мәң ꙁ**ә́**л-ләꙁ**и́** йә́шфәгъу гъы́йңдәһ**ү́** и́лл**ә́** би – иꙁниһ
( вакыф җә’из )
йә́гъләму м**ә́** бә́йнә әйд**и́**һим ўә м**ә́** х̲а́льфәһүм
( вакыф җә’из )
ўә л**ә́** йүх**и́**т̲**у́**нә би-шә́й’им мин гъы́йльмиһ**и** и́лл**ә**

www.darul-kutub.com

би́мə́ ш**ə́**’
( вакыф җə’из )
ўə́сигъа күрси́йййүһүс-сəмə́ўə́ти ўəл-ə́рдъ ( вакыф җə’из )
ўə лə́ йə’**ү**дүһү хифз̲ў́һүмə ( вакыф җə’из )
ўə һүўəл-гъали́йййүл-гъаз̲**ы́**йм(аятнең ахыры)

Вакыф җə’из - рөхсəт ителгəн вакыф димəк. Туктамасаң да була, əмма югарыда күрсəткəн тəртип буенча уку Коръəне – Кəримнең хакын үтəү була.
Аяттəге тукталышларның берсе – мотлак вакыф яки мəҗбүри тукталыш.
Сүз ( лə́һү мə́ фи́с-сəмə́ўə́ти ўə мə́ фил-əрдъ ) дигəн өлеш турында бара: “ -əрдъ” дигəч бераз туктап торырга кирəк.
Аятьнең ахыры “-гъазы́йм” сүзендə тəмамлана. Монда шулай ук бераз туктап торырга кирəк .

## Аятел – Көрсинең уку тəртибе

Аятел – Көрсине үзен генə яки əл – Бəкара сүрəсеннəн тыш, укыган вакытта килəсе тəртиплəрнең берсе кулланылыр:

أَعُوذُ بِاللّٰهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ ۞

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ۞

اَللّٰهُ لَآ اِلٰهَ اِلَّا هُوَ

www.darul-kutub.com

- “ Әгъуℨү бил – ләһи минәш – шәйтанир – ражим. Бисмил- ләһир – рахмәнир – рахим” дип Аятел – Көрсине укып җибәрерләр;

أَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ ۞

اَللّٰهُ لَآ اِلٰهَ اِلَّا هُوَ

- “ Әгъуℨү бил – ләһи минәш – шәйтанир – ражим” дип “Бисмил- ләһир – рахмәнир – рахим” әйтмиенчә Аятел – Көрсине укып җибәрерләр.

Шулай ук Аятел – Көрсине “Әгъуℨү бил – ләһи минәш – шәйтанир – ражим” әйтмиенчә “Бисмил- ләһир – рахмәнир – рахим” белән башлап укырга да мөмкин.

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ۞

اَللّٰهُ لَآ اِلٰهَ اِلَّا هُوَ

Һәрхәлдә, Аятел – Көрсине ничек укып китсәң дә “ Әгъуℨү бил – ләһи минәш – шәйтанир – ражим” белән башлапмы, әллә “Бисмил- ләһир – рахмәнир – рахим” беләнме, араларында бераз туктап тору хәерле булыр. Яки:

- “Әгъуℨү бил – ләһи минәш – шәйтанир – ражим” - (ТУКТАЛЫП ТЫН АЛУ) - **Әлла́һү лә́ илә́һә и́ллә һү** .....
- “ Әгъуℨү бил – ләһи минәш – шәйтанир – ражим.Бисмил- ләһир – рахмәнир – рахим” – (ТУК-ТАЛЫП ТЫН АЛУ) - **Әлла́һү лә́ илә́һә и́ллә һү** .....
- “Бисмил- ләһир – рахмәнир – рахим” - (ТУК-

www.darul-kutub.com

ТАЛЫП ТЫН АЛУ) - Әлла́һү лә́ илә́һә и́ллә һү ....

## Аятьнең мәгънәсе

Аллаһ! Аннан башка һичбер иләһ юк! Мәңге тере, мәңге бар булып, бернәрсәгә дә мохтаҗ булмаучы. Аны черем итү һәм йокы алмас. Күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә, һәркем - Аныкы. Рөхсәтеннән башка Аның алдында кем соң шәфәгатьче булыр икән? Алар алдында булганны да, алардан соң булачагын да Ул белеп тора. Аның теләгеннән тыш Аның гыйлеменнән һичбер элешкә дә ирешә алмаслар. Аның көрсие күкләр һәм җирне чолгап алган һәм аларны күзәтеп - саклап тору Аңа авыр түгелдер. Һәм Ул югары, бөек бит!

## Аятьнең инү сәбәбе

Аятел – Көрси төнлә ингән аяттер. Аять иңү белән Рәсүл Әкрәм ( саллэл – лаһү галәйһи вә сәлләм) хәзрәти Зәедне чакыртып ала һәм аятьне язма хәлгә күчертә.

Хәзрәти Мөхәммәд ибнел – Хәнәфиййә риваятенә күрә Аятел – Көрси иңгәч дөньяда булган һәр пот, мөшрикләрнең табына торган бүкәннәре егылганнар, ишелгәннәр; патшаларның башларындагы таҗлары башларыннан төшкән. Шәйтаннар исә бер берсеннән узып Иблис мәлгунь янына чапканнар, күргән хәлләр турында сөйләгәннәр. Иблис мәлгунь берничәсен Мәдинәгә җибәрә. Алар Мәдинәгә барып җиткәч анда Аятел – Көрси иңү турында ишетәләр. Шуңа күрә дә, Рәсүл Әкрәм ( саллэл – лаһү галәйһи вә сәлләм)

www.darul-kutub.com

хәзрәтләре бу аятьне Коръәни Кәримнең иң бөек аяте дип атаган да.
«Әй, Әбү Мүнзир! Коръән аятьләре арасында кайсысы иң бөектер?», - дип, Мөхәммәд галәйһис-сәлам сахәбәләренең берсеннән сораган. Ул: «Аллаһы Тәгалә һәм Аның Рәсүле яхшырак белүчеләрдер», - дип җавап биргән. Рәсүлүллаһ галәйһис-сәлам, сорауны берничә мәртәбә кабатлап сорагач сахәбә:

اَللّٰهُ لَآ اِلٰهَ اِلَّا هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ

« Әлла́һу лә́ илә́һә и́ллә һү»не («Аятел-Көрси»не) укып җибәргән. Рәсүлүллаһ ( салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) хәзрәтләре аңа:
“ Гыйлем иясе бәхетле булсын, ий, Әбү Мүнзир!Җаным хөкемендә булган Аллаһ Тәгалә белән ант итәмен ки, бу аятьнең Падишаһның гареше аяклары янында олылап торучы теле дә бар, иреннәре дә..» (хәдис-шәриф)
Хәзрәти Нәвеф әл – Бикәли бу аят хакында болай дигән: «Аллаһы Тәгалә Тәүратта бу аятьне “Вәлийүл – лаһ” ( яки Аллаһы Тәгаләнең якын дусты”) дип атаган. Бу аятьне укучы кешене күкләр – җирдә булган фәрештәләр “Газиз” ( гыйззәтле,хөрмәтле) дип атарлар»

## Аятьнең тәфсире

اَللّٰهُ

www.darul-kutub.com

Аллаһ - Раббыбыз, барлыкны юктан бар итеп яратучы.
Аннан башка һичбер илаһи көч, илаһи зат, хак мәгъбүд юк.
Аллаһтан башка һәрнәрсәгә кодрәтле булган беркем, бернәрсә юк та, була да алмый.
Аллаһ - Раббыбызның бөек исеме. Әмма бу Аның бердәнбер исеме генә түгел. Бу аяттә Раббыбызның биш исеме очрый.

## Аллаһы Тәгалә исемнәре хакында

Хәзрәти Фәхър әр-Рази, мәшһүр тәфсирче, болай дигән: «Бер борынгы китапта мин Аллаһы Тәгаләнең 4000 исеме бар икәнне укыдым, шуларның бер меңе Коръәндә һәм дөрес хәбәрләрдә зикер ителгән , бер меңе - Инҗилдә, бер меңе - Зәбурда, бер меңе - Тәүраттәдер». Бу нәрсә шулай булганны Пәйгамбәребез салләл-лаһү галәйһи вә сәлламнең бер догасыннан күреп була. Ул (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм) догасын болай кылган була: «Ий, Аллаһым! Хакыйкать ки, мин Синнән Үз - Үзеңне атаган һәр исемең белән, яки Китабында иңдергәне белән, яки мәхлукатларыңның берәрсен өйрәткән исемең белән үтенеп сорыйм...» Димәк, Аллаһы Тәгаләнең теләгән бәндәсенә һич беркемгә ачмаган берәр исемен өйрәтүе бар. Аллаһы Тәгаләнең берәр, аерым бәндәсенә ачкан андый исемне Исме – Әгъзам дип атыйлар.
Габдуллаһ ибне Гомәр (разыял - лаһү ганһүмә) рияять кыла: «Рәсүлүллаһ (салләл - лаһү галәйһи вә сәл-

ләм) Мәдинәдә чагында минбәрдә торып бернәрсәне Аллаһы Тәгаләдән тапшырып сөйләде (димәк, бу хәдис-кодси була): «Аллаһы Тәгалә Кыямәт көне булгач, күкләр вә җирне җыеп алыр да: «Менә шулай!» - дип, аларны кабат ныклап тотып алыр, шуннан җәеп җибәрер дә:

«Мин - Аллаһы,
Мин - Рахман,
Мин - Рахим,
Мин - Мәлик,
Мин - Куддус,
Мин - Сәлам,
Мин - Мүьмин,
Мин - Мүһәймин,
Мин - Газиз,
Мин – Җәббар,
Мин - Мүтәкәббир,

Мин дөньяны бернәрсә дә булмаган чагында бар иттем,
Мин - аны кабат элекке үз кыяфәтенә кайтаручы!
Кайда падишаһлар? Кайда җәбер кылучылар?», - дип сорар»

Борынгы китапларның берсендә риваять кылына: Аллаһы Тәгалә бәндәсенә болай диярдер: «Ий, бәндәм, син теләвен телисен, әмма Мин теләгән генә булыр. Әгәр син, Мин теләгән белән разый булсаң, Мин үзеңә җитәрлекне бирермен. Әгәр син, Мин теләгәнгә разый булмасаң, үзеңне булган хәлеңдә калдырырмын, соңыннан барыбер Үзем теләгәнчә булыр!»

www.darul-kutub.com

هو الله الذي لا إله إلا هو

الرحمن الرحيم الملك القدوس السلام المؤمن المهيمن العزيز الجبار المتكبر

الخالق البارئ المصور الغفار القهار الوهاب الرزاق الفتاح العليم القابض

الباسط الخافض الرافع المعز المذل السميع البصير الحكم العدل اللطيف

الخبير الحليم العظيم الغفور الشكور العلي الكبير الحفيظ المقيت الحسيب

الجليل الكريم الرقيب المجيب الواسع الحكيم الودود المجيد الباعث الشهيد

الحق الوكيل القوي المتين الولي الحميد المحصي المبدئ المعيد المحيي

المميت الحي القيوم الواجد الماجد الواحد الصمد القادر المقتدر المقدم

المؤخر الأول الآخر الظاهر الباطن الوالي المتعالي البر التواب المنتقم

العفو الرؤوف مالك الملك ذو الجلال والإكرام المقسط الجامع الغني المغني المانع الضار

النافع النور الهادي البديع الباقي الوارث الرشيد الصبور الله

Пәйгамбәребез ( салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) бер мөбәрәк хәдисендә болай дигән:«Хакыйкать ки, Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме бардыр. Кем булса да шуларны исендә калдырып санап китсә,җәннәткә керер. Ул, Аллаһы Тәгалә, бер Үзе генә, так булучы һәм такны ярата. Ул – Аллаһы Тәгалә, Аннан башка бер

илаһи Зат юктыр, әр-Рахмән, әр-Рахим, әл-Мәлик, әл-Куддүс, әс-Сәләм, әл-Мүьмин, әл-Мүһәймин, әл-Гъазиз, әл-Җәббәръ, әл-Мүтәкәббир, әл-Халик, әл-Бәри’, әл-Мусаўўир, әл-Гаффәръ,әл-Каһһәръ, әл-Ўәһһәб, әр-Раззәкъ, әл-Фәттәх, әл-Гъалим, әл-Кабидъ, әл-Бәситъ, әл-Хафидъ, әр-Рафигъ, әл-Мүгъыйзз,әл-Мүзилл, әс-Сәмигъ, әл-Бәсыйр, әл-Хәким, әл-Гъадль, әл-Ләтыйф, әл-Хабир, әл-Хәлим, әл-Гъазыйм, әл-Гафур, әш-Шәкүр, әл-Гъалийй, әл-Кәбир, әл-Хәфиз, әл-Мүгыйс, әл-Хәсиб, әл-Җәлил, әл-Кәрим, әр-Ракыйб, әл-Мүҗиб, әл-Ўәсигъ, әл-Хәким, әл-Ўәдүд, әл-Бәгъыйс, әш-Шәһид, әл-Хәккъ, әл-Ўәкил, әл-Каўийй, әл-Мәтин, әл-Мәҗид, әл-Ўәлийй, әл-Хәмид, әл-Мүхсый, әл-Мүбдий, әл-Мүгъыйд, әл-Мүхйий, әл-Мүмит, әл-Хәйй, әл-Каййүм, әл-Ўәҗид, әл-Мәҗид, әл-Ўәхид, әс-Самәд, әл-Кадир, әл-Мукътәдир, әл-Мүкаддим, әл-Му’әххыйр, әл-Әўўәл, әл-Әхыйр, әз-Заһир, әл-Бәтыйн, әл-Ўәлий, әл-Мүтәгъаль, әл-Бирр, әт-Тәўўәб, әл-Мүнтәкыйм, әл-Гъафуў, әр-Ра’уф, Мәликүл-мүлк, Зү-л-Җәләли ўәл-Икрам, әл-Мүкъсит, әл-Җәмигъ, әл-Ганий, әл-Мүгний, әл-Мәнигъ, әд-Дарр, ән-Нәфигъ, ән-Нур, әл-Һәдий, әл-Бәдигъ, әл-Бәкый, әл-Ўәрис, әр-Рашид, әс-Сабур» ( имам әл –Бохари вә имам Мөслим җыентыкларында китерелә)

## Аллаһы Тәгаләне тел белән олылау хакында

Раббыбызның “Әллаһ” дигән исем галимнәр фикеренчә Ләфза-и Җәлаләһ, ягъни Бөеклек, олы кодрәт

Хәзрәти Хәсән разыйал - лаһү ганһе, Мөхәммәд галәйһис-сәлам оныгы: «Кем дә кем «Аятел-Көрси»-не фарыз намазлардан соң укып тора икән, киләсе намазга кадәр Аллаһы Тәгаләнең саклавында булыр!», - дигәнне тапшырган.

*

«Тарих Бәгъдад» китабында Пәйгамбәр галәйһис-сәламнең Ибне Габбас (разыйал - лаһү ганһүмә) нең риваятенә күрә киләсе хәдис-шәрифе китерелгән: «Кем дә кем фарыз намазын тәмамлаган саен «Аятел-Көрси» укый икән - Аллаһы Тәгалә аңа шөкрана бәндәләрнең калебен, туры - рас сүз сөйләүчеләрнең гамәлләрен, пәйгамбәрләрнең әҗерләрен бирер. Ул бәндә Аллаһы Тәгалә рәхмәте астында булыр. Аңа җәннәткә китәргә килеп җитмәгән әҗәле генә комачаулап торыр»

*

Әбү Үмәмәһ разыял - лаһү ганһе риваять иткәнчә, Рәсүлүллаһ галәйһис-сәлам пәйгамбәребез: «Бер мөэмин, биш вакыт намаздан соң «Аятел-Көрси»не укыса, Аллаһы Тәгалә бу мөэминнең җанын нәкъ сугыш кырында шәһит булып киткән пәйгамбәрләрнең җаннарын алган шикелле алыр...», - дип әйткән.

*

«Әй, Гали! Һәр намаз артыннан «Аятел-Көрси» укысаң, шөкер итүчеләрнең калебе, пәйгамбәрләрнең савабы, изге күңеллеләрнең гамәлләре сиңа бирелер», - дигән пәйгамбәребез Мөхәммәд ( салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)

# Бәракәт арттыручы аят

Гайшә ана (разыял - лаһү ганһә) хәбәр иткән: «Берәү, Мөхәммәд (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм) янына килеп, өеннән бәрәкәт китүенә зарлана. Мөхәммәд салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм мескен кешегә: «Син «Аятел-Көрси»не күңелдән белмисеңмени? Син аны тәгам өстенә укыган саен, Аллаһы Тәгалә аның бәрәкәтен арттырып горыр!», - дип киңәш-нәсыйхәт биргән.

*

Сахәбәләрнең берсе әфәндебез Мөхәммәд галәйһис-сәлам хозурына барып: «Йә Рәсүлүллаһ! Өемдә бәрәкәт дигән нәрсә бер дә калмады!», - дигәч, Мөхәммәд галәйһис-сәлам: «Син, Аятел-Көрси»-не белмисеңме әллә? Ул ризык өстендә укылса, Аллаһ Тәгалә аның бәрәкәтен арттырыр. Ул сине дә, гаилә, өеңне һәм өең тирәсендәге башка йортларны да саклаячак. Сез аның файдаларын белсәгез, һич ташламас идегез! Яткан вакытта укысаң, җеннәрнең шәреннән котылырсың вә Ходай Тәгалә үзеңә ике фәрештәне вәкил итеп куяр, алар сине саклап торырлар!», - дигән.

*

Бәрәкәт арттыру өчен «Аятел-Көрси»не бер кисәк ефәк өстенә 313 мәртәбә укырлар, һәр «Аятел-Көрси» укыган саен укучы кеше шул кисәккә өрергә тиеш булыр. Укып бетерелгәч, бу ефәк кисәге йортның берәр югары урынына эленеп куелыр.



www.darul-kutub.com

## Саклаучы аят

Ибне Мәсгуд (разыйал - лаhү ганhе) риваятендә Рәсүл Әкрам салләллаhү галәйhи вә сәлламнең киләсе хәдис-шәрифе тапшырылган: «Берәү Мөхәммәд галәйhис-сәламнән: «Йә Рәсүлүллаh! Аллаhы Тәгалә Үземә берәр файда китерә торган нәрсә өйрәтсәң иде!» - дип үтенә. «Аятел-Көрси» не укып йөр! Ул үзеңне дә, гаиләңне дә, өеңне дә, хәтта тирә-юньдәге башка йортларны да бәладән саклап торыр», - дигән Пәйгамбәр галәйhис-сәлам хәзрәтләре.

*

Куркыныч бер урында яки явызлар арасында «Аятел-Көрси»не 21 мәртәбә укучы кешене Аллаhы Тәгалә аларның явызлыклардан коткарыр.

*

Әгәр җәмәгать эчендә булганда шул халыктан берәр зыян тияр дип курыксаң, 3 мәртәбә «Аятел-Көрси»не укы hәм учларыңа 3 мәртәбә өр дә йөзеңне сыпыр. Йөзен сыпырганда:

اَللّٰهُمَّ اكْفِنِى شَرَّ هٰؤُلَاءِ الْقَوْمِ

يَا كَافِى وَ عَافِنِى مِنْ آذَاهُمْ

يَا مُعَافِى

«Әллáhүммә әкфинú шәрра hә’ýләил-каум. Йә Кә́фи үә гъáфини мин әзáhүм йә мүгъáфи», - дип дога кыл.



www.darul-kutub.com

Ул кавемнән сиңа һич бер зарар - зыян да тимәс, иншәАллаһ.

## Йокы алдында уку

Хәзрәти Гали кәррамәл-лаһү үәҗһәһ тапшырган: «Пәйгамбәр салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм:
«Кем дә кем «Аятел-Көрси»не фарыз намазлар ахырында укып тора икән – аңа җәннәткә керүне бары тик әҗәл генә тыеп торыр.
Кем дә кем аны йокларга ятыр борын укыса, Аллаһы Тәгалә аның йортына да, күршесенең йортына да, тирә - юньдәге йортларга да иминлек бирер», - диде»
*
Хәзрәти Гали кәррамәл-лаһү үәҗһәһ: «Йоклар алдыннан «Аятел-Көрси»не укымаучы мөселманнарны аңлап бетермим.
Әгәр бу аятьнең хикмәтләрен белсәләр иде!
Әгәр аның Мөхәммәд салләл - лаһү галәйһи вә сәлләмгә Аллаһы Тәгаләнең гареше астындагы хәзинәләрдән бирелгәненнән гафил булмасалар иде! «Аятел-Көрси» Мөхәммәд салләл - лаһү галәйһи вә сәлләмгә кадәр бер пәйгамбәргә дә бирелмәгән иде! Мин дә «Аятел-Көрси»не укымыйча һич йокларга ятмыйм», - дигән.
*
Аллаһы Тәгалә әүлияләренең кайберләре өйрәткәнчә, йокларга ятучы кеше «Аятел-Көрси»не 3 мәртәбә укып ятса, куркыныч төшләрдән, җөн - пәриләрдән имин булыр, иншәАллаһ.

## Шәйтанны куучы аят

Әбү Һурайрә (разыял-лаһү ганһе) риваятенә күрә, Мөхәммәд салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм аны Рамазан аенда фитыр садәкасын (башка риваятьләр буенча зәкәт садәкасын да) сакларга, исәпләргә - хисапларга куя. Бер төнне берәү, килеп, шыпырт кына ризыкны (хөрмә, ярма) урлый башлый. Әбү Һурайрә (разыял-лаһү ганһе) аны тотып ала да: «Үзеңне хәзер Мөхәммәд салләл - лаһү галәйһи вә сәлләмгә озатам. Ул сиңа урлаганың өчен берәр хөкем чыгарыр», - дигән. Ләкин карак: «Гаилә-балаларым бик күп, хәлем калмады, шуңа күрә генә урлашуга кердем. Зинһар, җибәр инде үземне. Башка бу юлга басмамын!» - дип гозерләп сорагач, Әбү Һурайрә (разыйал - лаһү ганһе) аны җибәрә. Иртәгесен Пәйгамбәр галәйһис-сәлам Әбү Һурайрә разыял - лаһү ганһедән: «Төнлә килгән берәү нәрсә эшләде?», - дип сорый. Әбү Һурайрә(разыял - лаһү ганһе) барысын да ничек булган шулай сөйләп бирә. Мөхәммәд галәйһис-сәлам Әбү Һурайрә (разыял - лаһү ганһе)не: «Ул - ялганчы ич, янә килеп урлау кәсебенә керәчәк әле», - дип кисәтә. Киләсе төнне дә бу хәл кабатлана. Мөхәммәд галәйһис-сәлам Әбү Һурайрә (разыял - лаһү ганһе) бу хәлнең кабат булачагы турында янә хәбәр итә. Өченче төнне дә шул ук хәл кабатлангач, Әбү Һурайрә (разыял - лаһү ганһе) аны тотып Пәйгамбәр галәйһис-сәлам янына алып барырга булгач, теге: «Зинһар җибәрә күр үземне! Үзеңә Коръәннең бер аятен өйрәтермен, син

шуны төнлә укысаң, иртәнге сәгатькә кадәр үзеңә һичбер зарар да тимәс», - дия. Әбү Һүрайрә (разыял - лаһү ганһе) хәйран калып теге каракны җибәрергә була.
Карак Әбү Һүрайрә (разыял - лаһү ганһе) «Аятел-Көрси»не укып бирә дә үз юлы белән китеп бара. Иртәгесен Әбү Һүрайрә (разыял - лаһү ганһе) бөтенесен Мөхәммәд саллэл - лаһү галәйһи вә сәлләмгә сөйләп бирә. Мөхәммәд саллэл - лаһү галәйһи вә сәлләм: «Ялганчы булуына карамастан, бу юлы үзеңә дөресен әйткән», - дип бәя бирә каракның сүзләренә. Карак исә шайтан үзе булып чыга.
Шундый ук хәлләр күптөрле сахәбәләр белән була. Шуңа күрә өйдә әйберләр югала башласа, «Аятел-Көрси»не еш укый башларга кирәк! Ишек өстенә элеп куелган шәмаильдәге «Аятел-Көрси»не күңелдән белсәң инде, файдасын исәпләп бетерә алмассың, иншәАллаһ!
*
«Аятел-Көрси» кайсы гына йортта укылса да, 30 көн буена ул йорттан шайтаннар ерак булыр, 40 көн буена ул өйгә сихерчеләр, багучылар керә алмаслар. Йә, Гали! Бу аятьне улыңа да, гаиләңә дә өйрәт, күршеләреңә дә искә төшер! Коръәндә моннан изгерәк, хөрмәтлерәк, моннан да кадерле, бөегрәк аять юктыр» (хәдис-шәриф)
*
Әбү Һүрайрә (разыял - лаһү ганһе) әйткән: «Пәйгамбәр галәйһис-сәлам: «Әл-Бәкара» сүрәсендә Коръән

аятьләренең әфәндесе (иң олысы) урнашкан. Кайсы гына йортта ул укылса - шайтан аннан чыгып качар. Ул - «Аятел-Көрси»дер», - диде»

## «Аятел-Көрси»не хәсрәт вакытында уку

Әбү Катәдәһ тапшырган: «Рәсүлуллаһ салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм: «Кем дә кем хәсрәт вакытында «Аятел-Көрси» белән «Әл-Бәкара» сүрәсенең ахыргы 3 аятен укыса, Аллаһы Тәгалә ярдәменә ирешер», - дип әйтте».

## «Аятел-Көрси»нең фазыйләтләре хакында

«Аятел-Көрси»не бер мәртәбә уку мең аять уку белән бердер» (хәдис-шәриф)

*

«Бер мөэмин «Аятел-Көрси»не укыса, мөэминнәрнең әрвахларын шат кылыр, каберләренә нур иңдерер, каберләрен киң итәр. Укыган хәрефе саен берәр фәрештә яратылыр. Ул фәрештәләр Кыямәт көненә кадәр «Аятел-Көрси» укучыга истигфар догасын кылып торырлар» (хәдис-шәриф)

*

Хәзрәти Хәсән разыял - лаһү ганһе, пәйгамбәр Мөхәммәд салләл - лаһү галәйһи вә сәлләмнең оныгы, берәүнең төш күргәнен сөйли: «Берәү төшендә вафат булган кардәшен күрә. «Әй, кардәшем! Теге дөньяга күчтең, кайсы гамәлеңнең җимешен татлырак итеп тойдың?», - дип сорый аннан. Вафат булган кеше: «Коръән укуны», - дип җавап бирә. «Ә Коръәннең

кайсы урыны өстен булып күренде?» - дигәч, вафат булган туганы: «Аятел-Көрси», - дия. «Сез, мәетләр, безнең өчен берәр дога кыласызмы соң?» - дигәч, мәет булучы: «Әйе, кылабыз шул. Тик сез гамәл кыласыз, нәрсә булачагын белмисез генә. Без исә белеп торабыз, гамәл кылудан гына мәхрүм торабыз...», - дигән»

## Өйгә кергәч укыла торган «Аятел-Көрси»

Җәннәткә дөньялыгында ук ирешүче дип Пәйгамбәр галәйһис-сәламнең мактавына һәм илаһи вәгъдәгә ирешкән Габдуррахман ибне Гауф (разыял - лаһү ганһе) исемле сәхабә, өенә кергәч, почмак саен «Аятел- Көрси»не укый торган була.

## Өйдән чыкканда укыла торган «Аятел-Көрси»

Мөхәммәд галәйһис-сәлам хәзрәти Галигә (Аллаһы Тәгалә аның йөзен нурландырсын!) васыять итеп: «Кем дә кем өеннән «Аятел-Көрси» укып чыга икән, өенә кайтып җиткәнче Аллаһы Тәгаләнең химаясендә, яклавында булыр. «Аятел-Көрси» укылган йортка утыз көн буена шайтаннар якын килмәс, кырык көн буена сихерче ирләр һәм хатыннар да керә алмас. Ий, Гали! «Аятел-Көрси»не балаларыңа, хатыннарыңа, күршеләреңә өйрәт! Моннан да бөегрәк аять иңмәде әле! Берәү йокыга ятар алдыннан «Аятел-Көрси» укыса, Аллаһы Тәгалә аның үзен дә, күршесен дә, күршесенең күршесен дә, өе тирәсендә булган өйләр-



www.darul-kutub.com

не һәртөрле начарлыктан имин итәр. Сүзләрнең әфәндесе - Коръәндер. Коръәннең әфәндесе - «Әл-Бәкара» сүрәсе, «Әл-Бәкара» сүрәсенең әфәндесе исә - «Аятел-Көрси»дер», - дип әйтте.
Шулай ук, Пәйгамбәр галәйһис-сәлам хәбәр иткәнчә, өеннән чыкканда «Аятел-Көрси»не укучы кешене Аллаһы Тәгалә җитмеш мең фәрештәсенә тапшырыр. Ул фәрештәләр аның очен истигфар әйтеп торырлар, ди.

## Калеб күзләре ачылу хакында

Шәйхел - Әкбәр Гариф бил - ләһ Мөхйеддин Гарәби хәзрәтләре: «Кем дә булса көндезен, кичен меңәр мәртәбә «Аятел-Көрси» укуны кырык көн буена дәвам итә икән, Аллаһы Тәгалә белән ант итәмен, валлаһи, валлаһил-газыйм, Бөек Коръән белән, Аллаһның Рәсүле белән ант итәмен, ул кешенең рухы ачылып китәр, калеб күзләре ачылыр, фәрештәләр ул кеше янына килерләр, ул кеше һәр морадына ирешер...», - дигән.
Бөек «Аятел-Көрси»нең серләрен ачыклап, Сәгъдуддин Тәфтәзәни хәзрәтләре: «Берәү «Аятел-Көрси»не (эчендә булган хәрефләр санынча) берьюлы йөз җитмеш мәртәбә укыса, ул кешегә җирдә - күктәге мәхлукатлар, Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән, итагатьле булып, үзен һәр нәрсәдән саклап торырлар, ул кешегә дошманнар ни телләре, ни куллары белән зарар-зыян кыла алмаслар», - дип хәбәр итә.



www.darulkutub.com

## «Аятел-Көрси»нең серләре

Рәсүлүл - лаһ салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм «Аятел-Көрси»не көн саен 7 шәр мәртәбә укып, үзенә пәри - җен шәреннән иминлек сораган.

*

Төн уртасында кыйблага юнәлеп, 170 мәртәбә хәерле ният белән укылган «Аятел-Көрси» хакына теләкләр үтәлер, иншәАллаһ.

## «Аятел-Көрси» турында олы ишан – хәзрәтләр сүзе

Хәзрәти Баба Фәридуд - дин Җәнҗ (разыял - лаһү ганһе) болай дигән:

*

«Аятел-Көрси» - Коръәннең иң бөек аяте буладыр.

*

«Аятел-Көрси»не укучы, җеннәрнең шәреннән иртән кичкә, кичтән иртәгә кадәр иминлектә булыр.

*

«Аятел-Көрси»не уку Коръәннең дүрттән бер өлешен укуга тиң.

*

«Аятел-Көрси»не һәр фарыз намаздан соң укучыны җәннәткә керүдән әҗәл җитмәү генә тоткарлап торыр.

*

«Аятел-Көрси»не фарыз намаздан соң укучы кеше



www.darul-kutub.com

киләсе фарыз намазга кадәр иминлектә булыр.
*
«Аятел-Көрси»не ризыклар, су өстенә уку ризыкка да, суга да бәрәкәт бирер.
*
Өйгә кергәндә «Аятел-Көрси»не уку шайтанны өй бусагасы аркылы үткәрмәс.
*
«Аятел-Көрси»не укучының үзе дә, гаиләсе дә, малы да, өе дә, күршеләре дә иминлектә булырлар.
*
«Аятел-Көрси»не укучы янына карак якын килмәс.
*
«Аятел-Көрси»гә «Әл-Бәкара» сүрәсенең ахыргы аятләрен өстәп уку доганың мөстәҗаб булуына сәбәп булыр.
*
«Аятел-Көрси» берәр савыт өстенә укылса, ул савытны шайтан ача алмас.
*
«Аятел-Көрси»не йокларга яткан кеше укыса, ул, уянганчыга кадәр, 2 фәрештә карамагында булыр.
*
Әйберләр өстенә «Аятел-Көрси»не укып өрү аларны шайтаннан саклар.
*
Өйдән чыгучы кеше «Аятел-Көрси»не укыса, өенә кайтканчы Ходай ригаясендә булыр.
*

«Аятел-Көрси» белән «Әл-Муьмин» сүрәсенең аятьләрен иртән укучы кеше кичкә кадәр, кичен укучы иртәсенә кадәр имин булыр.

***********

Котбүд - дин Бәхтияр (рәхмәтүл – лаһи галәйһи) әйткән:

*

Аллаһы Тәгалә өйдән чыкканда «Аятел-Көрси»не укучы кешене мохтаҗлыктан коткарыр.

*

Авыру кешегә «Аятел-Көрси» укып өрсәләр, авыруга җиңеллек булыр.

*

Хастаханәдәге авырулар ята торган бүлмәгә «Аятел-Көрси»не укып өрсәләр, иншәАллаһ, авыруларга җиңеллек булыр.

*

Иминлек һәм бәрәкәт өчен «Аятел-Көрси»не 33 яки 99 мәртәбә укырлар.

*

Куркыныч төшләрдән интегүче кеше йокы алдыннан «Аятел-Көрси»не 3 мәртәбә укысын.

*

Җомга көннәрдә, икенде намазыннан соң,бер үзе, ялгыз булган урында «Аятел-Көрси»не 70 мәртәбә укучы кеше нур күрә башлар, догалары бу вакытта кабул булыр.



www.darul-kutub.com

## «Аятел-Көрси» шифасы

Явыз хуҗа каршына керер алдыннан «Аятел-Көрси»-не уку явызны телсез калдырыр.

*

«Аятел-Көрси»не зәгъфран, гөлчәчәк мае, мисек белән бер савыт эченә басма, тоташ булмаган хәреф-ләр белән язып, савытка су салып куйсын. «Аятел-Көрси»нең хәрефләре санынча Ходай ризалыгы өчен ураза тотып, шул су белән авыз ачсын, Аллаһы Тәгалә бу бәндәгә күптөрле хикмәтләр ачар.
Ураза токтан кеше авыз ачканда «Аятел-Көрси»не 7 мәртәбә укысын. Шуннан соң

اَسْئَلُكَ بِحَقِّ هَذِهِ الآيَةِ الشَّرِيفَةِ

اَنْ تُلْهِمُنِى عِلْمُكَ اللَّدُنِىِّ

يَا اَللهُ

«Әлла́һүммә инни әсьә́лүкә би-хәккый һә́зиһил-ә́й-этиш-шәри́фәти ән түлһимни гъыйльмүкәл-лэдүний. Йә Әлла́һ», - дип дога кылсын.

## «Аятел-Көрси»нең зыяндаш авыруын шифалау

Зыяндашы кузгалган кешенең баш очына «Аятел-Көр-си»не 11 мәртәбә уку зыяндашын басарга яхшы чара булыр, иншәАллаһ.

www.darul-kutub.com

## «Аятел-Көрси»нең мәеткә булышуы

Мәет кәфененең баш очына, уртасына һәм аяклары тирәсендә һавада бармак белән «Аятел-Көрси» язылса, мәетнең сөаль вакыты җиңел үтәр һәм ул, шул хөрмәтле аять хакы белән, кабер газабын да күрмәс, иншәАллаһ.

## Ачу чыккан вакытта «Аятел-Көрси»не уку

Кем дә кем «Аятел-Көрси»не ачуы чыккан вакытта укыса һәм шуннан сул ягыннан төкерсә - янындагы шайтан чигенер һәм ачуы басылыр.

## 313 «Аятел-Көрси»

Мәгълүм ки, «Аятел-Көрси»дә 170 хәреф бар, бу аять 50 сүздән тора. Шуңа күрә, галимнәр бу аятьне берьюлы 50 яки 170 мәртәбә укырга дип киңәш иткән булалар.Шулай ук «Аятел-Көрси»не берьюлы 313 мәртәбә, ягъни Әсъхәб Талут (Талут юлдашлары, ярдәмчеләре) һәм Бәдер сугышында катнашкан сахәбәләр санынча укырга да тәкъдим иткәннәр.
Һәм дә Пәйгамбәребез салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм исемнәре санынча, ягъни 201 мәртәбә уку да дөрес булыр.

www.darul-kutub.com

## Морадларга ирешер өчен «Аятел-Көрси» уку

Теләкләргә ирешү максаты белән бу Аятьне укыгач,

وَلَا يَؤُدُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ ۞

«Ўә лә́ йәʾүдүһү хифзуһүмә́ ўә һүўәл-гъалиййүл-гъазыйм» дигән сүзләрне берьюлы 70 мәртәбә укырлар, шуннан кабат аятьнең башына кайтырлар һәм, бу сүзләргә җиткәч, янә аларны 70 мәртәбә кабатларлар. Һәм, тәмамлагач, дога кылып, Аллаһы Тәгаләдән кирәкләрен сорарлар.

## Йокы тыныч булсын өчен

Тыныч кына йоклар өчен, төрле хавефле төшләр белән интекмәс өчен Бисмил-ләһир-рахмәнир-рахим әйтеп 3 мәртәбә Аятел-Көрси, Аятел-Көрсинең һәр кайсысында

وَلَا يَؤُدُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ ۞

дигән өлешен 3 әр мәртәбә кабатлап уку кирәк. ИншәАллаһ, йокы тыныч булыр.

## Ел буена имин булыйм дисәң...

Кем дә булса Мөхәррәм әл - Хәрам аеның беренче

www.darul-kutub.com

көнендә 1 мәртәбә Әгъузү-бисмилләсен әйтеп 360 мәртәбә «Аятел-Көрси» укып, Һәр укылган «Аятел-Көрси»дән соң:

اَللّٰهُمَّ يَا مُحَوِّلُ الْاَحْوَالِ حَوِّلْ حَالِى

اِلٰى اَحْسَنِ الْاَحْوَالِ بِحَوْلِكَ وَ قُوَّتِكَ

يَا كَبِيرُ يَا مُتَعَالُ يَا عَزِيزُ يَا مِفْضَالُ

وَ صَلَّى اللهُ عَلٰى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ

وَ عَلٰى آلِهِ وَ صَحْبِهِ وَسَلِّمْ

«Әллаһүммә йә мүхәўўилүл-әхьўәл хәўўил хәли илә әхсәнил-әхьўәл би-хәўликә ўә куўўәтикә йә кәбир, йә мүтәгъаль, йә гъазиз, йә мифдаль ўә салләл-лаһү гъалә сәййидинә Мухәммәд ўә гъалә әлиһи ўә сахьбиһи ўә сәллим», - дип дога кылса, әлеге кеше бу ел дәвамында курыкканыннан иминлектә, тынычлыкта булыр, иншәАллаһ.

www.darul-kutub.com

күрсәткеч исеме була.

Раббыбызның Әллаһ исеме Аның, ягъни Бер Аның исеме генә, бердәнбер Аңа гына хас булган исемедер. Гореф-гадәт буенча Әллаһ (татар халкы бу исемне "Аллаһы" дип атый) дигән исемнән соң киләсе гыйбарәләр кую гаять күркәм һәм әҗерле эш булыр:

- Аллаһы Тәгалә
- Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре
- Аллаһы Җәллә Җәлаләһү
- Аллаһы Сүбхәнәһү вә Тәгалә хәзрәтләре
- Аллаһы Газзә вә Җәллә хәзрәтләре
- Аллаһы Галә Шәьнәһү

## Әллаһ исеме

Дәвамлы хәлдә "Әллаһ, Әллаһ" дип зикер кылучының күнеле нурга гарык булыр.

Җомга намазыннан соң берәр урында бер үзе ялгыз булып, 100 мәртәбә "Йә Әллаһ! Йә Һү!" дип зикер кылса морадына ирешер, 1000 мәртәбе шулай зикер кылса иманы куәтләнер.

Кәгазьгә 70 мәртәбә "Йә Әллаһ" дип язып, шуннан бу кәгазьне чишмә суы тутырган савыт эченә салсалар һәм бераз вакыт үткәч бу суны авуга эчерсәләр , иншәАллаһ, шифасы булыр.

Кояш байганчы " Әллаһ" дип берәр кәгазь, тире, тукыма өстенә язып шул язманы янында йөртсән шәйтан шәреннән имин булыр.

www.darul-kutup.com

لَا إِلٰهَ إِلَّا هُوَ

**Аннан башка һичбер илаһ юк!**

( тәфсирнең дәвамы)

Галәмнең, безнең хисләр белән тыйганын, күргәнен, таныганын да, без күрмәгәнен, тыймаганын, танымаганын да яратучысы яки Халикы бар.

Бу яратучы, Халик – илаһ була.

Җир йөзендә, тирә - юнь мохиттә без, әдәм балалары күзәтә ала торган һәрнәрсә, безгә күренгән һәм күзләр күрә алмаган, хисләр тойган һәм тоя алмаган һәркемне, һәр нәрсәне Халикъ булучы, юктан бар итеп яраткан. Галәмне барлыкка китерүче Аллаһы Тәгалә аны яраткан, булдырган һәм иҗат кылган.

Безнең тормышыбыз, яшәүебез, ризыгыбыз, сәламәтлегебез,кыскасы, һәрнәрсә бары тик Аның рәхмәтеннән тора, шул рәхмәтнең кадерен белүчеләр иман бәхетенә ирешүчеләр була.

Аллаһ Тәгалә – Бердәнбер, Бер һәм Бар илаһ.

Ул бары тик Үзе генә илаһ.

Аннан башка һич беркем, бернәрсә дә Аның дәрәҗәсенә җитә алмый.

Аллаһ Тәгаләнең һич бер шәриге яки уртагы, баласы, хатыны, ата - анасы юк.

Бөтен барлык яки безнең күрә, тоя алганы да, күрә, тоя алмаганы да, һәр нәрсә, һәркем – Аның хөкемендә.

Һич беркем дә үз - үзенә хуҗа була алмас.

www.darulkutub.com

Һич беркем дә икенче берәүгә «син оҗмахка керәчәксең,ә син исә, тәмугта яначаксың!»,- дип хөкем чыгара алмас.

Бәя бирү, хисап кылу – Аллаһы Тәгаләнең хөкемендә генә.

Ул теләгән нәрсә генә була, Ул теләмәгән нәрсә һич берничек тә була алмас.

Бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә чын, камил мактау, хәмед - сәнә хас, тиеш һәм лаеклы.

Бары тик Аллаһы Тәгалә генә тереклек бирә, Аның әмере белән җан кертелә, Аның әмере белән генә җан чыга.

Шул ук вакытта, бары тик Ул Үзе генә мәңге тере, Аның мәңгелегенең очы – кырые, чиге, ахыры юк. Аллаһы Тәгалә мәңге тере , үлмәс, армас, талмас.

Аңа йокы, ял итү хас нәрсә түгел.

Аңа шулай ук ару - талу дигән нәрсә дә хас түгел.

Һәр игелек, хәерлек, яхшылык – Аннан гына. Аллаһы Тәгалә золымны, гаделсезлекне, һәртөрле начар, әшәке сыйфатлар, фигыльләрне сөймәс.

Аллаһы Тәгалә һәр кемгә үз ихтыяры белән гамәлен кылырга ирек бирә, шуннан соң һәр кем үз, ирекле ихтыяры белән кылган гамәленә күрә Аллаһы Тәгалә каршында җавап тотачак.

Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәгә кодрәтле дию Аллаһы Тәгаләнең камил, мотлак (абсолют) кодрәт иясе булуны тану димәк.

Аның булдыра алмый торган нәрсәсе юк,хәленнән килмәс нәрсә мөмкин түгел.



www.darul-kutub.com

الْحَىُّ

## Мәңге тере

Мәңге тере дигән сүзләр киләсе фикерне күрсәтәдер: һәрнәрсәнең, һәркемнең башы - ахыры, тууы - үлеме бар.

Кайбер нәрсәләр, күренешләр кайчандыр, бик борынгы заманда башланып, бүгенге көнгә кадәр, Кыямәт көненә кадәр дәвам итәчәк. Ләкин ахырында барыбер юк булачак, бетәчәк, үләчәк. Аллаһы Тәгалә исә - мәңге тере.

Мәшһүр "Гыйбадәте Исламия" китабында Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларын ачыклап хәзрәти Әхмәд Һади Максуди: "Хәййү – тере дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә тере, ләкин Аның тереклеге безнең кебек тән һәм җан сыман түгел", - дигән.

Инде "ләкин Аның тереклеге безнең кебек тән һәм җан сыман түгел", - дию Аллаһы Тәгаләнең тере булуы мәхлүкларның тере булуы белән бер булмаганын аңлатадыр.

Мәхлүклардан аерма буларак, Аның тере булуының башы да, башланып киткән вакыты да, ахыры да юк. Әгәр алай булмаса, Раббыбыз - Халикъ (юктан бар итеп яратучы) Аллаһы Тәгалә булмас иде. Димәк, Аллаһы Тәгалә - мәңгедер.

Аның ахыры да, үлеме дә юк.

Үлем вакыты , әҗәле җиткәч юк булу мәхлукатлар сыйфатыннандыр, Аллаһы Тәгалә исә мәңге тере булучы.

www.darul-kutub.com

## Әл-Хәйй исеме

Әл-Хәйй - мәңге терек, тереклегендә беркемгә һәм бернәрсәгә дә мохтаҗ булмаган, тереклегенең башы - ахыры булмаган илаһи зат.

1. Бу исем-шәрифне берьюлы 300 мең мәртәбә укып чыккан кеше һич авырмас. Бу исем-шәрифне шулай ук берәр су өстенә укысалар яки шул сулы савыт эченә бу исемне язган кәгазьне салсалар, һәм бу суны авыру кешегә 3 көн буена эчерсәләр, авыру шулай ук шифаланыр.

2. Бу исемне кат-кат дәвамлы хәлдә укучы кеше матур гомер кичерер.

3. Эч пошудан, төрле авырулардан интеккән кеше 5 кояш чыкканчыга кадәр 500 мәртәбә бу исемне дәвамлы хәлдә укыса - бу аңа шифа бирер,

ٱلْقَيُّومُ

## мәңге бар булып, бернәрсәгә дә мохтаҗ булмаучы

Әл-Каййүм - бар булып, булуында беркем, бернәрсәгә дә мохтаҗ булмаган, илаһи Зат. Шул ук вакытта һәркем, һәрнәрсә Аның булуына мохтаҗ булучы.

Ул Үзенең бар булуында бернәрсәгә, беркемгә дә мохтаҗ түгел. Мохтаҗ булу - мәхлукатлар, ягъни юктан бар итеп яратылган нәрсәләрнең, кемсәләрнең сыйфатларыннан. Әйтик, корып кипкән җир мул яңгырга мохтаҗ, имчәк баласы сөткә мохтаҗ, атка печән

www.darulkutub.com

кирәк, шәкерткә гыйлем, китап кирәк. Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәгә, һәркемгә, тәннәребезгә дә, җаннарыбызга да хуҗа булып, Үзе бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел, мохтаҗ була да алмый.

Һәрнәрсәгә кодрәтле булып, һәрнәрсәне булдырып, һәрнәрсәне белеп торып, һәрнәрсәгә Үз теләге белән ризыгын, әҗәлен бирүче Аллаһы Тәгалә - Халикъ, Тәңребез берничек тә мохтаҗ була алмый. Бу сыйфат ягъни мохтаҗсызлык, бернәрсәгә дә мохтаҗ булмау - Аллаһ Раббыбызга гына хас булган сыйфат.

## Әл-Кайййүм исеме

Әл-Кайййүм - бар булып, булуында беркем, бернәрсәгә дә мохтаҗ булмаган, әмма һәркем, һәрнәрсә Аның булуына мохтаҗ булган илаһи Зат.

* Зиһене зәгыйфьләнгән кеше бу исемне «Йә Кайййүм» дип 16 шар мәртәбә дәвамлы хәлдә укыса, иншәАллаһ, кальбе дә нурланыр, зиһене дә артыр.

* Ялкаулыктан интегүче кеше иртәнге азаннан соң кояш чыкканчыга кадәр Исрафил галәйһис-сәлам зикерен күпләп укысын: «Йә Хәйй! Йә Кайййүм би-рахмәтикә әстәгыйсү!»

* Бу исемне күпләп укучы кеше теләкләренә җиңел ирешер, мөшкеллек күрмәс, иншәАллаһ.

## Исме – Әгъзам

Мәгълүм ки, Пәйгамбәребез (саллә л – лаһү галәйһи вә сәлләм), югарыда китерелгән хәдис - шәрифендә, Аллаһы Тәгаләнең 99 күркәм, гүзәл исемен (әл -



www.darul-kutub.com

Әсмә'үл - Хүснә) атап киткән. Бу исемнәрдән башка Аллаһы Тәгаләнең иң бөек (гарәпчә «Әгъзам» димәк) исеме дә бар. Бу исем хакында галимнәр арасында төрле - төрле фикер бар. Нәкъ Кадер кичәсенең төгәл вакыты, көне вә төне кайчан икәнлеге мәгълүм булмаган шикелле, Исме - Әгъзамның төгәл кайсы исем булганы да билгесез. Нәкъ Кадер кичәсе Рамазан - шәрифнең 27- нче кичәсендә булуы ихтимал дип аны 21 - нче кичәдә дә, 23-нчесендә дә, 25-нчесендә дә, 29-нчысында да ихтимал булуын һич беркем дә инкар итми. Шуның шикелле Исме Әгъзам буларак Аллаһы Тәгаләнең фәлән исеме дә, башка бер исеме дә, һәм башка бер исеме дә дип исәплиләр.Әмма төгәл буларак Исме Әгъзамның кайсысы икәнен белмәсләр.

Пәйгамбәребез(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең бер хәдис-шәрифендә: «Бисмил - ләһир - рахмәнир - рахим» белән Исме-Әгъзам арасында нәкъ күзнең агы белән кара арасында шикелле ара булыр»,– диелгән.

Күп чыганакларга күрә, Исме Әгъзам ул «Әллаһ» дигән исем буладыр. Кайбер хәбәр - әсәрләргә күрә Исме Әгъзам «Әллаһүммә» дип әйтү буладыр. Галим хәзрәтләрнең фикеренчә, Аллаһы Тәгаләнең Исме Әгъзамы «әл-Хәййүл - Каййүм» исемнәре булыр. Хәдисләрдән бер нәрсә билгеле: Рәсүлуллаһ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)не берәр нәрсә борчыса ул «Йә Хәйй! Йә Каййүм! Бикә әстәгыйсү» (Ий, Мәңге терек булучы! Ий, һич беркемгә дә, бер нәрсәгә дә мохтаҗ булмыенча бар булучы! Синнән ярдәм сорыймын!»),– дип шул исемнәр белән дога кыла торган



www.darulkutub.com

була. Икенче бер хәдис-шәрифтә Рәсүл - Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) «Йә Хәйй, йә Каййүм», - дип дога кылган.

لَا تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلَا نَوْمٌ

## Аны черем итү һәм йокы алмас

Аллаһы Тәгаләгә черем итү, йоклап алу, ару – талу, ял итү дигән нәрсәләр дә ят. Болар барысы да адәм, хайван, җанварларга гына хас. Шул ук вакытта җирдә, күктә, без белгән-белмәгән галәмдә булган һәрнәрсә, һәркем Аллаһы Тәгаләнең карамагы, хөкеме астында тора.

Һәркем, һәрнәрсә Аның рәхмәтенә, илтифатына, мәрхәмәтенә мохтаҗдыр.

Ибне Габбас разыял - лаһү ганһүмә хәзрәтләре тапшырган бер кыйссадан Бәни Исраилнең Муса галәйһис-сәлам пәйгамбәргә мөрәҗәгать итүе мәгълүм була. Алар: «Йә Муса! Синең Раббың йоклап аламы?»,- дип сорыйлар. Муса галәйһис-сәлам: «Аллаһы Тәгаләдән куркыгыз инде! Мондый сорау бирәсез», - дип җавап бирә. Әмма Аллаһы Тәгалә: «Йә Муса! Алар синнән, Раббың йокларммы, дип сорыйлар. Син ике кулыңа ике пыяла савыт тотып, төнне аягүрә үткәр!», - дип әмер бирә Муса галәйһис-сәламгә. Муса галәйһис-сәлам шулай эшли дә. Йокысы килә, иснәнә башлый, төннең ике өлешен чыдар - чыдамас шулай үткәрә. Төннең өченче өлешендә түзә алмыйча йокы-

www.darul-kutub.com

га китә, аның кулыннан ике савыт та төшеп ватыла... Аллаһы Тәгалә Муса галәйһис-сәлам аркылы яһүдләргә:

«Ий, Муса! Әгәр Раббың синең шикелле йокласа, җире дә, күкләре дә шулай егылып җимерелерләр иде дә һәркем, һәрнәрсә һәлак булыр иде!», - дип җавап бирә...

Димәк, Аллаһы Тәгалә мәңге армас - талмас, ял итмәс, һәм ял итүгә мохтаҗ да түгел.

## Китап сүзе

Исраиль угыллары яки яһүдиләр беркөнне Муса галәйһис-сәла́мгә мөрәҗәгать итеп: «Ий, Муса! Синең Раббың намаз укыймы?», - дип сорыйлар. Муса галәйһис-сәла́м, Аллаһы Тәгаләнең тәкъвалы бәндәсе буларак, һәм яһүдләрнең тәкъвалы булуларына өметләнеп: «Ий, Исраиль угыллары! Ягъкуб галәйһис-сәла́м варислары! Аллаһы Тәгаләдән куркыгызчы!», дип аларны үгетли. Аллаһы Тәгалә яһүдийләрнең Муса галәйһис-сәла́мгә нәрсә әйткәнен белеп, аннан: «Ий, Муса! Кавемең сиңа нәрсә дип әйтте?», дип сорый. Муса галәйһис-сәла́м: «Ий Раббым! Син Үзең белгәнчә! Алар: «Синең Раббың намаз укыймы?»,-дип әйттеләр»,- диде. Аллаһы Тәгалә: «Ий, Муса! Син аларга хәбәр ит! Хакыйкатьтә, Минем намазым, ий бәндәләрем, рәхмәт-мәрхәмәтемнең ачуыма караганда алдан булуында. Әгәр шулай булмаса, Мин аларны һәлак итәр идем!»,- дип хәзрәти. Муса Кәлимуллаһ галәйһис-сәла́мгә әмер иткән.



www.darulkutub.com

لَهُ مَا فِى السَّمٰوٰتِ وَمَا فِى الْأَرْضِ ۗ

## Күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә, һәркем – Аныкы

Күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә, һәркем – Аның мәхлүклары. Шуңа күрә күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә, һәркем – Аныкы яки Аның хөкемендә. Имам Әбу Мәнсур әл – Мәтүриди (рахмәтүл – лаһи галәй-һи) бу аятьнең мәгънәсен аңлатып: "Аллаһы Тәгалә-нең "Күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә, һәркем – Аныкы" дигән сүзләре күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә, һәркем анын коллары, бәндәләре булуны ачыклый. Әмма бу коллык, бәндәчелек кешеләр-нең "фәлән фәләннең ир баласыдыр", "фәрештәләр Аллаһы Тәгаләнең кыз балаларыдыр" дию белән бер түгел. Аларның җөмләсе Аллаһы Тәгаләнең коллары, бәндәләре.Кешеләр колларындан үзләренә бала ал-маганны, Аллаһы Тәгалә шулай эшләмәүгә тагын да хаклырак була", - дип әйткән. Бу сүзләрне имам Әбу Мәнсур әл – Мәтүриди ( рахмәтүл – лаһи галәйһи)нең "Тәәвиләт Әһлис – Сүннәһ" дигән тәфсирендә таба аласыз.

Аяттәге "Күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә, һәр-кем – Аныкы" дию Аллаһы Тәгаләнең мәхлүкларына ишарә.

Күктәгеләре фәрештәләр, җөннәр, башка төрле мәхлүклар булса, җирдәгеләре – кешеләр, җөннәр, кош – кортлар, коры һәм су хайваннары, күзгә күрен-

мәгән микроблар, хәтта исемләрен белмәгән, кузгә күренмәгән мәхлүклардыр.

مَنْ ذَا الَّذِى يَشْفَعُ عِنْدَهُۥٓ اِلَّا بِاِذْنِهِ ۚ

## Рөхсәтеннән башка Анының алдында кем соң шәфәгатьче булыр икән?

Шәфәгать ни димәк?

Шәфәгать Кыямәт көнендә гөнаһкярләрнең гөнаһларын кичерергә, гафу итергә, тиешле газап, лаеклы җәзадан саклап калу, аклау дигән сүз. Шәфәгать кылу хакына ирешкән кеше яки шәфәгатьче ”гафу итсәң иде, ут белән җәзаларга тиеш булуына карамастан җәннәткә кертсәң иде!”, - дип Аллаһы Тәгаләдән фәлән улы фәлән яки фәлән кызы фәлән өчен үтенер. Кем дә кем Аллаһы Тәгалә тарафыннан шәфәгать кылу мөмкинлегенә ирешсә, Аннан шәфәгать иясе булырга рөхсәт алса - аның дәлилләрен Раббыбыз искә алыр. Шуннан кем башка берәүгә шәфәгатьче булыр, һәм шәфәгатьче булырга лаек икәнен Бер Үзе генә белүче - Аллаһы Тәгалә. Әмма хәдис – шәрифләргә күрә шәфәгатьче булырга:

- Мөхәммәд ( галәйһис – сәламгә) хак бирелер;
- башка пәйгамбәр – рәсүлләргә хак бирелер;
- чын галимләргә хак бирелер;
-чын шәһит кешеләргә хак бирелер (Аларның һәркайсысы нәселендә булган 70 гөнаһкяргә шәфәгатьче булу хакына ирешер);

- чын мөәззиннәргә хак бирелер;
- хәлалне хәлал итеп, хәрамны хәрам итеп таныган, гыйлем өйрәнеп гамәлен гыйлеменә күрә башкарган кешеләргә хак бирелер;
- чын хаҗиларга хак бирелер .

Мондый хаҗиләрнең һәркайсысы нәсел – токымында булган 400 гөнаһкяргә шәфәгатьче булу хакына ирешер.Әлбәттә, шәфәгатьче булу хаклары башка төрле кешеләргә дә Аллаһы Тәгалә әмере белән насыйп булуы ихтимал үәл- лаһү әгъләм.

## Пәйгамбәребез (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)нең шәфәгате хакы турында

Хәдисләр белгече, олы галим хәзрәтләрнең берсе, Габдел-Хак әд-Дәһләви (Аллаһның рәхмәтендә булсын!) шәфәгатьнең берничә төрлесе бар дип сөйләгән.

Шәфәгатьләрнең беренчесе, иң олысы әфәндебез Мөхәммәд (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)гә генә хас булганы. Шәфәгатьнең бу төрлесе һич башка бер пәйгамбәр, рәсүлгә насыйп булмас. Шәфәгатьнең бу төрлесеннән җир йөзендә яшәгән һәркем, Аллаһы Тәгалә рөхсәте булса, файдалана алыр.

Шәфәгатьнең икенче төрлесе шулай ук Пәйгамбәребез (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)гә генә хас. Шәфәгатьнең бу төре хисапсыз хәлдә яки хисап тотмыенча җәннәткә керергә юл ачар.

Шәфәгатьнең өченче төрлесе әҗерләре - сәваплары гөнаһ-кимчелекләре белән бертигез килгән халыкка



www.darulkutub.com

таралыр. Шәфәгатьнең бусы андый халыкка җәннәткә керергә хак бирер.

Шәфәгатьнең дүртенче төрлесе утка, тәмугка керергә лаеклы булган халыкка тәмугка кермиенчә җәннәткә үтергә мөмкинлек бирер. Пәйгамбәребез (са́ллəл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм): “Шәфәгатем өммәтемдә булган олы гөнаһ ияләренә булыр”, - дигән. Бу хәдис – шәриф әт – Тирмизи, Әбу Дауд һ. б. хәдис җыентыкларында китерелгән.

Шәфәгатьнең бишенче төрлесе оҗмахка керергә тиешле халыкның дәрәҗәсен тагын да югарырак булганга алыштыра алыр.

Шәфәгатьнең алтынчы төрлесе утка кергән халыкның мөселман булганнарын уттан алып чыгып җәннәткә кертергә рөхсәт бирер.

Шәфәгатьнең бу төрлесе шулай ук Пәйгамбәребез (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)нән башка гайре пәйгамбәрләргә, рәсүлләргә, фәрештәләргә, галимнәргә, шәһид888ләргә биреләчәк.

Шәфәгатьнең җиденче төрлесе җәннәтнең бикләнгән капкаларын ачып җибәрер.

Әлбәттә, Пәйгамбәребез (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)гә биреләчәк шәфәгатьнең башка төрлере дә булыр. Әйтик, җәһәннәмдә мәңгегә калган халыкның газапларын бераз киметү белән бәйле шәфәгать яки мөшрикләрнең сабый балаларына карата кулланачак шәфәгать.

Хәзрәти Мөслимнең «әл-Җәмигъ әс-Сахих» исемле хәдисләр җыентыгында хәзрәти Әбу Һүрәйра



www.darulkutub.com

разыял-лаһу ганһе тарафыннан риваять ителгән хәдис-шәриф китерелгән: «Рәсүлүллаһ салләл-лаһу галәйһи вә сәлләм: «Кыямәт көнендә мин адәм угылларының әфәндесе булачакмын. Ә нәрсә өчен икәнлеген беләсезме? Аллаһы Тәгалә бер урында әүвәлгеләрен дә, ахырдан булганнарын да җыеп туплаячак. Шуннан алар бер чакыручы авазын ишетерләр һәм бер күз карашы алар аша үтәр. һәм кояш якынаер. Кешеләрне гамь - хәсрәт шулкадәр басар ки, хәтта аңа чыдарга, аны кичерергә тәкатьләре калмас...
Шул вакыт кайбер кешеләр икенчеләренә: «Үзегез белән нәрсә килеп чыкканын күрмисезме әллә? Раббыгыз алдында үзегезне яклар, шәфәгать үтенердәй затны эзләп карамассызмы икән?», - диярләр. Шуннан берәүләре икенчеләренә: «Адәм галәйһис-сәламгә барып карагыз!»,- диярләр. Алар Адәм галәйһис - сәлам янына барырлар һәм аңа: «Йә, Адәм! Син - безнең атабыз! Син - кешелек, бәшәрият атасы ич, Аллаһы Тәгалә сине Үз кодрәте белән юктан бар итеп яратты, Үзенең рухыннан сиңа жан өреп кертте, каршыңда фәрештәләргә сәҗдә кылырга әмер итте һәм алар сәҗдә кылдылар! Син безнең ни хәлдә булганыбызны күрмисеңме әллә? Безнең нинди хәлгә җиткәнебезне күрмисеңме әллә? Раббың каршында безнең өчен шәфәгатьче булсаң иде!», - дип мөрәҗәгать итәрләр... Адәм галәйһис-сәлам: «Хакыйкать ки, Раббымның бүген һич бер кайчан булмаган хәлдә ачуы чыккан, моңа кадәр дә, моннан соң да Ул болай ачулы булмас, Ул миңа агач җимешен тыйган иде, әмма мин тыңла-

мадым, мәгъсыять кылдым... Ий, Аллаһым! Үзем белән ни булыр! Юк, мин сораганыгызны булдыра алмыйм! Нух галәйһис-сәлам янына барып карагыз!», - дигән сүзләр белән кешеләрне борып җибәрер...

Шуннан кешеләр Нух галәйһис-сәлам янына килерләр һәм: «Йә, Нух! Син җир йөзендә рәсүлләрнең беренчесе, Аллаһы Тәгалә сине шөкранә бәндә дип тә атады, Раббыбыздан шәфәгать үтенсәң иде, син безнең ни хәлдә булганыбызны күрмисеңме әллә? Безнең нинди хәлгә житкәнебезне күрмисеңме әллә?», - дип мөрәҗәгать итерләр.

Нух галәйһис-сәлам исә аларга: «Хакыйкать ки, Раббымның бүген һич беркайчан булмаган хәлдә ачуы чыккан! Моңа кадәр дә, моннан соң да Ул болай ачулы булмас, минем инде халкыма җиткерергә тиешлесе белән мөрәҗәгать иткәнем булды, сезнеке белән Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итәрлек хәлем юк. Ий, Аллаһым! Үзем белән ни булыр?! Ибраһим галәйһис-сәлам янына барып карагыз!», - дип кешеләрне кире борып җибәрер...

Шуннан кешеләр Ибраһим галәйһис-сәлам янына барып аңа: «Йә, Ибраһим! Син - Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәре дә, җир йөзендәге халык арасында булган Аның якын дусты да! Безне яклаучы булсаң иде, безгә шәфәгатьче булсаң иде! Син безнең ни хәлдә булганыбызны күрмисеңме әллә? Безнең нинди хәлгә җиткәнебезне күрмисеңме әллә?», - дип кагылып карарлар... Ул исә: «Хакыйкать ки, Раббымның бүген һич беркайчан булмаган хәлдә ачуы чыккан, моңа



www.darul-kutub.com

кадәр дә, моннан соң да Ул болай ачулы булмас», - дип ул, галәйһис-сәлам, үзенең турында кешеләр сөйләгән ялганнарны искә төшерде дә: «Ий,Аллаһым! Үзем белән ни булыр! Юк, миннән башкага барыгыз! Әнә, Муса янына барып карагыз!», - диячәк. Шуннан кешеләр Муса галәйһис-сәлам янына барырлар да: «Йә, Муса! Син Аллаһы Тәгаләнең рәсүле, Аллаһы Тәгалә үзеңне Тәүрат иңдерү белән хөрмәтләде, синең аша кешеләргә Сүзен белгертте... Син безнең ни хәлдә булганыбызны күрмисеңме әллә? Безнең нинди хәлгә җиткәнебезне күрмисеңме әллә? Раббың каршында безнең өчен шәфәгать кыл!», - дип мөрәҗәгать итәрләр. Әмма Муса галәйһис-сәлам: «Хакыйкать ки, Раббымның бүген һич беркайчан булмаган хәлдә ачуы чыккан, моңа кадәр дә, моннан соң да Ул болай ачулы булмас, мин әмер ителмәгән кеше үтердем ич! Ий, Аллаһым! Үзем белән ни булыр! Гайсә янына барыгыз!», - дип кешеләрне борып җибәрер... Шуннан соң алар Гайсә галәйһис-сәлам янына барырлар да: «Йә, Гайсә! Син - Аллаһы Тәгаләнең рәсүле, кешеләр белән бишектә сөйләштең. Мәрьйәм анага бирелгән Аның кәлимәсе, Аннан булган рух! Раббың каршында безнең өчен шәфәгатьче булсаң иде! Син безнең ни хәлдә булганыбызны күрмисеңме әллә? Безнең нинди хәлгә җиткәнебезне күрмисеңме әллә?», - дип үтенерләр. Гайсә галәйһис-сәлам исә: «Хакыйкать ки, Раббымның бүген һич беркайчан булмаган хәлдә ачуы чыккан, моңа кадәр дә, моннан соң да Ул болай ачулы булмас!» дип генә һич берәр

гөнаһ, шелтәне дә искә алмыенча җавап бирер. «Ий, Аллаһым! Үзем белән ни булыр! Миннән башкасына барыгыз! Мөхәммәд саллəл - лаһу галәйһи вә сәлләм янына барыгыз!».

Шуннан алар үземнең яныма килерләр дә: «Йә, Мөхәммәд! Син Аллаһы Тәгаләнең рәсүле дә, пәйгамбәрләрнең мөһере, ахыргысы да. Аллаһы Тәгалә сиңа элекке гөнаһларыңны кичерде. Раббың каршында безнең өчен шәфәгать кыл сана! Син безнең ни хәлдә булганыбызны күрмисеңме әллә? Безнең нинди хәлгә җиткәнебезне күрмисеңме әллә?», - дип үтенерләр. Мин юлга кузгалырмын да Аның Гарше астына кадәр җиткәч, Раббым каршында сәҗдәгә китермен.

Шуннан соң Аллаһы Тәгалә үземә миңа кадәр һич беркемгә дә ачмаган, белгертмәгән, Үзенең рәхмәт - данлыкларын ачыр һәм: «Йә, Мөхәммәд! Башыңны күтәр! Сора - сораганың бирелер! Шәфәгать кыл, шәфәгатьчелек кабул ителер!» , - дип әйтер.

Мин исә башымны күтәреп: «Өммәтем, йә Рабби! Өммәтем өчен сорыймын, йә Рабби!», - дип сорармын.

Шуннан соң: «Йә, Мөхәммәд! Өммәтеңнән өсләрендә хисап бул¬маган кешеләрне җәннәткә уң яктагы ишекләр аркылы керт, алар исә башка кешеләргә башка ишекләр аркылы керергә булышырлар!»

Хөкемендә җаным булган Аллаһы Тәгалә белән ант итәмен ки, җәннәтнең ике ишекләре арасы нәкъ Мәккә белән Һәҗәръ яки Мәккә белән Бусра арасы кебек ераклыктыр...», - дип сөйләде»

www.darulkutub.com

## Дуснының шәфәгате хакында

Хәзрәти Җәбер ибне Габдуллаһ разыял - лаһу ганһе хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһү- галәйһи вә сәлләмнән киләсе хәдисне тапшырган: «Җәннәттә булучы бер кеше: «Раббым дустым фәләнне кая куйган икән?», - дип әйтер, ди. Дусты исә бу вакытта тәмугта булыр. Аллаһы Тәгалә шул вакытта: «Бу бәндәнең дустын янына җәннәткә алып керегез!» - дип әмер итәр. Бу хәлне тәмугтагы башка халык күреп:

فما لنا من شافعين

ولا صديق حميم

фәм**ә́** лә́н**ә́** миң ш**ә́**фигъ**ы́**йнә 100
ўә л**ә́** <u>с</u>ад**и́**<u>к</u>ыйн хәм**и́**миң 101

100. һәм безнең шәфәгатьчеләребез дә юк!
101. Һәм ихлас якын дустыбыз да! («әш-Шугъара») дип әйтерләр...

«Шуңа күрә, - ди хәзрәти әл-Хәсән разыял - лаһу ганһе - иман әһеленнән булган дусларыгыз күп булсын! Кыямәт көнендә аларның шәфәгате кабул ителер!»

يَعْلَمُ مَا بَيْنَ أَيْدِيهِمْ وَمَا خَلْفَهُمْ

**Алар алдында булганны да, алардан соң булачагын да Ул белеп тора**

www.darul-kutub.com

Аллаһы Тәгалә һәр мәхлүкларының, яратканнарының нәрсә кылганнарын, нәрсә кылачакларын белүче.
Хәзрәти Мүҗәһид аятьнең бу өлеше киләсе мәгънә бирә дигән: “Алар алдында булганны да яки дөньяда кылганнарын да, алардан соң булачагын да яки аларны әхыйраттә нәрсә көткәнен дә Ул белеп тора”.
Хәзрәти Ибне Габбас исә аятьнең бу өлеше: “Алар алдында булганны да яки дөньяда кылганнарын да, алардан соң булачагын да яки вакытларын заяга калдырып, кылмый калдырганнарын да Ул белеп тора” , - дигән мәгънәне бирер дип аңлаткан.
Хәзрәти әл – Хәсән әл – Басрый “Алар алдында булганны да” , “алардан соң булачагын да” гамәлләрне кылган һәм тәмамлаган ниятләр белән бәйле дигән.

وَلَا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلَّا بِمَا شَاءَ

## Аның теләгеннән тыш Аның гыйлеменнән һичбер элешкә ирешә алмаслар

Аллаһы Тәгалә - галим. Аның гыйлеме – мотлак, камил, чиксез. “Галим – белүче дигәнне аңлата”, - дигән хәзрәти Әхмәд Һади Максуди Аллаһы Тәгаләнең гыйлеме белән бәйле булган сыйфатларын ачыклап. “Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәне белә: булган нәрсәләр дә, булачак нәрсәләр дә – бөтенесе Аллаһы Тәгаләгә билгеле. Аллаһы Тәгаләгә мәгълүм булмаган нәрсә юк. Аның белүе безнең кебек өйрәнү, уйлану рәвешендә түгел”.

www.darul-kutub.com

Аллаһы Тәгалә рөхсәтеннән башка беркем дә бернинди дә гыйлем - хикмәткә ирешә алмас. Раббыбыз каршында фәрештәләр: “ Сөбхәнал – лаһ! Аллаһы Тәгалә һәр кимчелектән, җитешсезлектән пакьтер! Син Үзең безне өйрәткәннән башкасын без белмибез!” , - икърар кылмадылармы? Шуңа күрә башыбызда булган гыйлемнәр Аллаһы Тәгалә тарафыннан рөхсәт ителгән микъдарда, кәсебебез белән ирешә торган нәрсә булыр. Бусы – гыйлемнең бер төрлесе, ачык булганы. Аның башка бер өлеше дә бар: анысы – яшерен гыйлем. Гыйлемнең яшерен өлешен Аллаһы Тәгалә Үзе теләгән бәндәләренә генә ачыр.
Аллаһы Тәгалә - заманның, вакытның хуҗасы. Хәтта бер кодси хәдистә: «Заманны сүкмәгез, хурламагыз. Мин Үзем - мәңгелек!» - дип, Аллаһы Тәгалә адәм балаларын нык кисәтә. Аллаһы Тәгалә булганны, бар булучыны һәм булачакны Бер Үзе генә белүче.

## Гыйлем хакында

Хәзрәти әл-Бурусәвинең остазы: «Пәйгамбәрләрнең гыйлеме белән чагыштырганда, әүлияләрнең гыйлеме җиде диңгез янындагы бер тамчы шикелледер.Бөтен пәйгамбәрләрнең гыйлемен хәзрәти Рәсүлүллаһ саләллаһү галәйһи вә сәлләм гыйлеме белән чагыштырсаң, җиде диңгез янындагы бер тамчы шикелледер.
Рәсүлүллаһ салләл-лаһү галәйһи вә сәлләмнең белемен Аллаһы Тәгалә белеме янына куйсаң, нәкъ җиде диңгез янындагы бер тамчы шикелле булыр», - дигән.

وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمَٰوَٰتِ وَالْأَرْضَ

## Аның көрсие күкләр һәм җирне чолгап алган

Көрси ни димәк? Падишаһ, солтан, хан булучының хөкемдар булу күрсәткечләре бар. Шуларның берсе гареш яки тәхет була. Көрси - гарешнең алдында падишаһның аякларын куя торган урын. Аллаһы Тәгалә - Мәликүл – мүлк яки барча Барлык Падишаһлыгының Падишаһы, Солтаны, Хуҗасы. Димәк, Аның падишаһлыгының, падишаһ, солтан булуының күрсәткечләре булу кирәк. Гареш, көрси – мөнә шундый күрсәткечләрдән булалар. Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә ул гарешкә, көрсигә мохтаҗ түгел. Без , Мәккә - и Мөкәррәмәдәге Кәгъбәтүллаһны Бәйтүллаһ яки Аллаһы Тәгалә йорты дип атыйбыз. Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә ул йортка мохтаҗ тугел, ул йорт бары тик аның Хуҗасы бар икәнне генә күрсәтә. Шуңа күрә, мөхтәрәм җәмәгател – мөслимин, көферлектән саклана күрегез! Аллаһы Раббыбыз гарешкә дә, көрсигә дә мохтаҗ түгел: Аллаһы Тәгалә гарешкә дә, көрсигә утырып тормас, аларда урнашмас, урын алмас. Утыру, урын алу, берәр нәрсәгә яки кемсәгә мохтаҗ булу – мәхлүкларга гына кагыла, Халик исә андый күренешләрдән пакь! Инде башкача уйлау яки Аллаһы Тәгалә гареш – көрсигә мохтаҗ, аларга утырган, алардан югары булып урын алган һ.б. шундый шәйтани фикергә бирелү – иман зәгыйфьлегенә сәбәб булуы бар.

# Аллаһы Тәгалә көрсие

Аллаһы Тәгаләгә көрси кирәкме соң?

Юк. Көрси - кирәклектән булган нәрсә түгел. Көрси - Аллаһы Тәгалә кодрәтенең бер күрсәткече, дөньяларны, җир-күкләрне чорнап айкап алган нәрсә.

«Йә, Әбу Зәрр! Әгәр син җиде күк белән җиде җирне Аллаһы Тәгаләнең көрсие белән чагыштыра калсаң, җиде җир, җиде күк, көрси каршында, нәкъ иксез-чиксез җиргә ташланган бер балдак шикелле генә булырлар! Гарешнең көрсидән булган өстенлеге исә нәкъ шул иксез - чиксез җирнең ташланган балдактан булган өстенлеге шикелле булыр!», - дигән Пәйгамбәр галәйһис-сәлам Әбу Зәрр разыял - лаһү ганһе исемле сахәбәгә.

Әйе, көрсидән башка Аллаһы Тәгаләнең әле гареше дә бар. Аның бөеклеген, олылыгын, Пәйгамбәр галәйһис-сәлам әйткәнчә, сөйләп тә бетерә торган түгел.

Көрси гареш алдындагы нәкъ аяклар куя торган кечкенә генә эскәмия шикелле күренер. Аллаһы Тәгалә көрсие белән җир - күкләрне чолгап алган һәм күзәтеп тора. Хәтта безнең организмдагы, су тамчысындагы миллионлаган күзгә күренмәс җанварлар да - барысы да Аның күзәтүе астында. Бер бала артыннан да карап торырга бик авыр әле, Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәне, һәркемне, күзгә күренгән-күренмәгәнне, хис итә алган - алмаганны бөек гыйлеме белән белеп тора, белеп торуы мәшәкать тә китерми...



www.darul-kutub.com

## Көрси хакында бер-ике сүз

Көрси Аллаһы Тәгаләнең кодрәтен, бөеклеген тас¬вир итәр өчен булдырылган. Көрси - бер дәрәҗәле зат утыра торган урындык алдында аякларны куя торган урын. Әлбәттә Аллаһы Тәгаләнең көрсие Аңа утырып торыр өчен кирәкмәс!

Аллаһы Тәгалә - урын, заман төшенчәләреннән мөнәззәһ, пакь (ягъни бу нәрсәләр Аңа хас түгел!) Карагыз әле! Аллаһы Тәгаләнең җир йөзендә иң иске борынгы йорты (Кәгъбәтуллаһ) бар, көн саен дистәләп-йөзәрләп яңа йортлар (мәчетләр) ачылып тора! Шуннан, Кәгъбәтуллаһның бер почмагына Кара таш урнаштырылган. Ул - Аллаһы Тәгаләнең җир йөзендәге күзәтүчесе! Күпме халык көн саен, Аллаһы Тәгаләнең кунагы булып, Аның йортына бара! Күпме халык Аллаһы Тәгаләнең күзәтүчесе, кара ташны, нәкъ галим, хәзрәтләрнең кулларын үпкән шикелле, барып аны үбәләр...

Димәк, көрси дә Аллаһы Тәгаләнең дөньядагы Кодрәтен күрсәтүче бер олы җисем генә! Аллаһы Тәгалә - аны бары тик кодрәт-куәтен күрсәтер өчен генә яраткан. «Җиде кат күк һәм җиде кат җир, - дигән Рәсүлуллаһ салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм, - Көрси янында чүлнең уртасында булган бер йөзек шикелледер. Хакыйкать ки, Гарешнең көрсидән булган өстенлеге нәкъ шул чүлнең балдактан булган өстенлеге белән бердер».

Хәзрәти Мүкатиль разыял-лаһү ганһе хәбәренчә, көрсине 4 фәрештә йөртер диелгән. Ул фәрештәләрнең

аяклары 7 кат җирнең иң астагысында торалардыр, һәр кайсысы арасында юл 500 ел алыр. Шул фәрештәләрнең берсе Адәм галәйһис-сәлам кыяфәтендәдер, ул адәм угыллары өчен бер еллык ризык белән яңгыр үтенеп дога кыла торыр. Фәрештәләрнең икенчесе - сыер, өченчесе - арыслан, дүртенчесе - картал кош кыяфәтендә. Болар һәркайсысы үзенең кыяфәтендәге хайван - кош (ягъни йорт хайваннары, кыргый хайваннар, кош-корт) өчен еллык ризык, суын таләп итеп, Ходайга дога кылып торырлар...

Шундый булуына карамастан, бу көрси булсын, аннан да олырак булган гареш булсын, ди ул: «Мөэмин бәндәнең күңеле белән чагыштырганда ул нәкъ күк белән җир арасында элеп куйган бер балдак шикелле генә булыр!», - диелгән «Тәэвиләти Нәҗмиййәһ» китабында. Моның мәгънәсе исә, Аллаһ Раббуль-Гыйззәнең:«Мине күкләрем дә, җирем дә сыйдырмас, Үземне мөэмин бәндәм калебе сыйдырыр!» - дигән хәдис -кодсиенә барып тоташа. Димәк, чын иман әһеленең күңеле гареш - көрсидән дә олырак, бөегрәк!

## Күкләр саны

Хәзрәти Сәлман әл-Фәриси радыял-лаһү ганһе риваятендә әйтелгәнчә, күкләр җидәүдер.

1 нче кат Ракыйгъ дип атала, ул яшел төсле зөбәрҗәт матдәсеннән булыр.

2 нче кат Әрфәлүн дип атала, бу кат ап-ак көмеш матдәсеннәндер.

3 нче кат Кайдүм дип атала,бу кат кызыл якут мат-

дәсеннәндер.
4 нче кат Мәгъун дип атала, ул ак энҗедән булыр.
5 нче кат Дибка дип атала һәм ул кызыл алтыннандыр.
6 нчы кат Нәүфә дип атала, сары якуттандыр.
7 нче кат Гъурубәдер, ул бер төрле нурдан яратылган. Бу хакта хәзрәти Җәлалүддин әс – Суйутый ның тәфсирендә әйтелгән.

## Нәрсә өчен күкләр саны җиде, җир саны бер генә диелгән?

Коръәни Кәримнең 133 урынында сүз 7 кат күк һәм бер җир турында бара. Җир үзе бер аерым җисем (планета) булса да 7 каттан тора. Сәфәрдә булып, берәр яңа урынга, шәһәр яки авылга килеп кергәндә Пәйгамбәр ( галәйһис – сәлам) хәзрәтләре:

اللّٰهُمَّ رَبَّ السَّمٰوَاتِ السَّبْعِ وَمَا أَظْلَلْنَ

وَرَبَّ الأَرَضِينَ السَّبْعِ وَمَا أَقْلَلْنَ

وَرَبَّ الشَّيَاطِينَ وَمَا أَضْلَلْنَ

وَرَبَّ الرِّيَاحِ وَمَا ذَرَيْنَ

اَسْئَلُكَ خَيْرَ هٰذِهِ الْقَرْيَةِ وَخَيْرَ اَهْلِهَا

www.darulkutub.com

وَخَيْرَ مَا فِيهَا

وَاَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهَا وَشَرِّ اَهْلِهَا

وَشَرِّ مَا فِيهَا

“Йә, Аллаһым!
Җиде кат күк һәм алар каплаганнарның Раббысы!
Җиде кат җир һәм алар өсләрендә күтәреп торганнарның Раббысы!
Шәйтаннар һәм алар адаштырганнарның да Раббысы!
Җилләр һәм алар туздырганның Раббысы!
Синнән бу карьянең ( яши, тора торган урынның) хәерлеген, аның әһелләренең хәерлеген һәм анда булганның хәерлеген сорыймын. Һәм дә Сиңа аның шәреннән (начарлыгыннан) , аның әһелләренең шәреннән һәм анда булганның шәреннән ярдәм сорап сыенамын!”, - дип дога кыла торган була.

Бу догадан җир катларының саны җиде булганы күренә.

Шулай ук, Пәйгамбәр ( галәйһис – сәлам) хәзрәтләре бер мөбәрак хәдисендә: “Кем дә кем бер карыш зурлыгында җиргә карата золым кылса - аны җиде кат җир чорнап алыр”, - дигән.

Бу хәдис нәкъ шушы күренешне ачыклый дип әйтергә кирәк.

Хәзерге заман фән ачышлары шулай ук без яши торган Җир җиде каттан торганны раслыйлар. Аларның исемләре исә киләсе булыр:

www.darulkutub.com

1 нче кат Фираш дип атала.
2 нче кат Карар дип атала.
3 нче кат Ратк дип атала.
4 нче кат Бисәтъ дип атала.
5 нче кат Миһәд дип атала.
6 нчы кат Садгъ дип атала.
7 нче кат Кифәт дип атала.

وَلَا يَؤُدُهُ حِفْظُهُمَا ۚ

**һәм аларны күзәтеп саклап тору Аңа авыр түгелдер.**

Аллаһы Тәгалә өчен мөмкин булмаган нәрсә юк. Шуңа күрә күкләрдә, җирдә, алар арасында булган һәркем, һәрнәрсәне күзәтеп тә, саклап та тору , Аның өчен һич авыр түгел, мөшкел түгел. Һәркем, һәрнәрсә үзенә тиешле,билгеләнгән ризыгын кәсеп итә,гамәлләр белән шөгылләнә, игелек кыла.

Җирдәге агачларның бер яфрагы да Аның карамагыннан тыш төшмәс, ярма шытып чыкмас, кош очмас, кар яумас...

Һәрнәрсә, һәркем Аның карамагында, Аның күзәтүендә, Аның саклауы астында.

وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ ۝

**Һәм Ул югары, бөек бит!**

Аллаһы Тәгаләнең югары булуы нииндидер ара, бөеклек, югары булу белән бәйле түгел.

www.darul-kutub.com

Ул Үзенең илаһи дәрәҗәсе, кодрәте, дәүләте белән һәрнәсәдән дә югары.
Илаһи дәрәҗәсе, кодрәте, дәүләтенең иге - чиге, күләме булмауы белән бөек.
Ничек кенә булмасын ди, Аллаһы Тәгаләнең заты, сыйфатлары турында кирәгеннән арттырып фикер йөртү – ярамас эш.
Рәсүлүллаһ( саллэл – лаһү галәйһи вә сәлләм) хәзрәтләре өммәтен кисәтеп: " Аллаһы Тәгаләнең Үзе турында уйга бирелмәгез , Аның мәхлукы турында уйланыгыз!", - дип хөсне – нәсыйхат биргән.
Адәм баласы, мәлгунь Иблис котыртуы белән Аллаһы Тәгалә турында читтән чыгып уйланып, ниһаять , катгый тыелган уй - фикер йөртә башлауы бар. Алай эшләде икән – көферлеккә юл ачыла.

## Әл – Гъалий исеме

* Бу исем-шәрифне язып, язуын янында йөртүче кешенең хөрмәте югары күтәрелер.
* Бу исем-шәрифне язып, язуын янында йөртүче кеше ерак илләрдән ватанына сау-сәламәт килеш кайтыр.
* Бу исем-шәрифне язып, язуын янында йөртүче кеше фәкыйрьлектән котылыр.
* Дәвамлы хәлдә бу исемне укып йөрүченең холкы күркәм булыр, кешеләр алдында күркәм булып күренер.
* Бу илаһи исемне вирд ясап тоткан кешенең хикмәте артыр, гыйльме тирән булыр, халык арасында дәрәҗәсе үсәр.

* Ризык тарлыгыннан интеккән кеше бу исем-шәриф-не дәвамлы хәлдә укысын.

## Әл-Гъазыйм исеме

Бу исемне мөһим эшләр башлар алдыннан укырлар. Курыккан вакытта кем дә булса бу исемне 12 мәртәбә укып тән-җәсәденә өрсә, куркуы юкка чыгар, иншаллаһ.

Бу исемне күп-күп зикер итүче кеше халык арасында хөрмәт иясенә әйләнер.

Бу исемне «Йә Гъазы́йму җә́ллә җәлә́ләһү» дип зикер кылучының зиһене куәтле булыр, олы хөрмәт иясенә әйләнер, иншаллаһ. Авыручыларга бу исемне укысалар, иншаллаһ, авырулар җиңеллек тоярлар.

## «Аятел-Көрси» эчендә булган илаһи мәсьәләләр

Бу мөбарәк аять эчендә Аллаһы Тәгаләнең барлыгы - берлеге белән бәйле булган күпме хикмәт тулган! Карагыз, бу аять:

1. Аллаһы Тәгаләнең барлыгын - берлеген исбатлый.
2. Аның илаһилыгы - бердәнбер.
3. Аллаһы Тәгалә тере һәм беркемгә, бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел.
4. Аның булуы - ваҗиб!
5. Ул - яратучы, юктан бар итүче.
6. Үзе беркем, бернәрсәдә мохтаҗ булмыйча, һәркем,



www.darul-kutub.com

һәрнәрсә Аңа мохтаҗ.
7. Аллаһы Тәгалә - урыннан, мәхлук сыйфатларыннан пакь.
8. Аллаһы Тәгалә берәр нәрсә кыяфәтендә булудан имин.
9. Аллаһы Тәгалә - Үзгәрмәс илаһи Зат.
10. Зәгыйфьлек, көчсезлек - Аңа хас түгел.
11. Йокламас, черем итмәс.
12. Аның белән мәхлукатлар арасында һич бер охшашлык юк.
13. Нәфес, җаннарга хас нәрсәләр Аллаһы Тәгаләгә хас түгелләр.
14. Аллаһы Тәгалә - мөлек һәм мәләкүт (падишаһлык) Хуҗасы.
15. Диннең нигезләрен - ысул, форугъларын - Ул билгеләгән.
16. Аллаһы Тәгалә тумады һәм тудырмады.
17. Ул - көч - кодрәт Иясе.
18. Аллаһы Тәгаләнең җәзасы бик ныктыр.
19. Аның каршында рөхсәте булмаган хәлдә беркем икенче берәүгә шәфәгать кыла алмас.
20. Аллаһы Тәгалә генә һәрнәрсә турында белүчедер.
21. Ачык булганы да, яшерене дә Аның хөкемендә булалар.
22. Һәрнәрсәне Ул тулысынча белер.
23. Падишаһлыгы, кодрәте, гыйльме һәрнәрсәне айкап алган.
24. Аның теләгәненнән башка һич беркем Аның гыйлеменә ирешмәс.

## Гарше Газыйм хәзинәләреннән булган аят

* Әнәс разыял - лаһү ганһе риваятенә күрә Пәйгамбәр галәйһис-сәлам: «Аятел-Көрси» миңа Аллаһы Тәгаләнең гареше астыннан бирелде», - дигән.

## Иң бөек аят

* Үбәйй ибне Кәгъб хәбәр иткән: «Пәйгамбәр ( салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм)нән берәү: «Йә Рәсүлүллаһ, Аллаһы Тәгалә Китабында кайсы аять иң бөек булыр икән?» - дип сораган. Пәйгамбәр саллэл - лаһү галәйһи вә сәлләм: «Аятел-Көрси» («Көрси» аятедер)... Җаным Аның хөкемендә булучы Аллаһы Тәгалә белән ант итәмен, ул аятьнең теле дә бар, ике ирене дә бар. Аллаһы Тәгаләнең гареше аягы янында тәсбих әйтеп тора...», - дигән»

## Олы байлык

* Хәзрәти Әнәс (разыял - лаһү ганһе) тапшыра: «Рәсүлуллаһ саллэл - лаһү галәйһи вә сәлләм сахәбәләренең берсеннән: «Син өйләндеңме әле?», - дип сораган. «Йә Рәсүлүллаһ! Өйләнерлек хәлем юк ич!», - дип җавап бирә теге кеше. Рәсүлуллаһ саллэллаһү галәйһи вә сәлләм аннан: «Әллә «Кольһүәллаһ»-ны белмисеңме?» - дип сорый.

- Беләмен, йә Рәсүлүллаһ саллэл - лаһү галәйһи вә сәлләм!

- Димәк, син Корьәннең дүрттән бер өлешен беләсең! «Куль йә әййүһәл-кәфирун»ны беләсеңме?

- Беләмен, йә Рәсүлүллаһ саллэл - лаһү галәйһи вә сәлләм!

- Димәк, янә Коръәннең дүрттән бер өлешен белә сең ич! «Изә зүлзиләтил-әрду зилзәләһә» сүрәсен беләсеңме?
- Беләмен, йә Рәсүлүллаһ саллəл - лаһү галәйһи вә сәлләм!
- Ий, Коръәннең тагын дүрттән бер өлешен беләсең икән! Ә «Изә җә’эн-нәсърул-лаһи»ны беләсеңме?
- Беләмен, йә Рәсүлүллаһ!
- Монысы Коръәннең дүртенче өлеше. «Аятел-Көрси»не беләсеңме соң?
- Беләмен, йә Рәсүлүллаһ!
- Алай булгач, бар! Өйлән! - дип, Мөхәммәд галәйһис-сәлам сахәбәгә әмер иткән»

## Фарыз намазлар алдында «Аятел-Көрси»не уку

Берәү «Аятел-Көрси»не намаз башлар алдыннан укыса, шайтан ул кешенең янына намаз вакытында якын да килмәс. Аллаһы Тәгалә ул кешене дөньядагы бәла-казалардан, һәлакәт-фәлакәтләрдән, шайтанның шәрреннән имин итәр.

## «Аятел-Көрси»не намаздан соң уку

Әнәс хәзрәт разыял - лаһү ганһе тапшырган: «Рәсүлүллаһ галәйһис-сәлам: «Кем, һәр фарыз намазын укып бетергәч, «Аятел-Көрси» укыса - киләсе намазга кадәр иминлектә булыр. Ләкин пәйгамбәрләр, рас сүзлеләр, шәһитләр генә шулай булдыра алырлар», - дигән».



www.darulkutub.com